ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«04» февраль 2021 ел № 17-р

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында
«Татарстан чаңгы юлы-2021» массакүләм чаңгы ярышлары үткәрү турында

Чаңгы узышларын популярлаштыру һәм үстерү, халык арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, физкультура-савыктыру һәм спорт-массакүләм эшне камилләштерү, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә этәргеч бирә торган шартлар тудыру, иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында ярышларда катнашучылар арасында спорт осталыгын арттыру максатларында:

1. Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенә 2021 елның 13 февралендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Орешник» паркы территориясендә «Татарстан чаңгы юлы - 2021» массакүләм чаңгы ярышларын оештыру һәм үткәрү.

2. Расларга:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында “Татарстан чаңгы юлы - 2021” массакүләм чаңгы ярышлары үткәрү турында Нигезләмә (1 нче кушымта).

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында “Татарстан чаңгы юлы - 2021” массакүләм чаңгы ярышлары үткәрү турында чыгымнарның сметасы (2 нче кушымта).

3. Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенә:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Орешник” паркында массакүләм чаңгы ярышлары үткәрү урынын әзерләүне оештырырга;

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында «Татарстан чаңгы юлы - 2021» массакүләм чаңгы ярышларында медицина ярдәмен күрсәтүне тәэмин итәргә.

4. МКУ «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе»нә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләренә «Татарстан чаңгы юлы - 2021» массакүләм чаңгы ярышлары уздыру турында хәбәр итәргә һәм аларның катнашуын тәэмин итәргә.

5. «Татмедиа» ААҖ филиалының «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы редакциясенә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында «Татарстан чаңгы юлы - 2021» массакүләм чаңгы ярышларын уздыру, ярышларның барышы

һәм йомгаклары турында массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга тәкъдим итәргә.

6. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
04.02.2021 № 17-р
карарына 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында “Татарстан чаңгы юлы - 2021” массакүләм чаңгы ярышлары үткәрү турында Нигезләмә

### 1. Максатлар һәм бурычлар.

Ярышлар түбәндәге максат белән уздырыла:
-Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында чаңгы ярышларын популярлаштыру һәм үстерү;
-сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;
- физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә мотивацияли торган шартлар тудыру;
-иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау;
-Ярышларда катнашучыларның спорт осталыгын арттыру.

### 2. Үткәрү сроклары һәм урыны.

Ярышлар 2021 елның 13 февралендә уздырыла:
Әгерҗе шәһәре – “Орешник” паркы. Ярышларда катнашучыларны җыю һәм теркәү 10.00 сәгатьтән
Ярышлар 11.00 сәгатьтә башлана.
Әгерҗе районы - Бима авылы. Ярышларда катнашучыларны җыю һәм теркәү 10.00 сәгатьтән
Ярышлар 11.00 сәгатьтә башлана.

### 3. Ярышлар белән җитәкчелек итү һәм уздыру.

Ярышларның гомуми җитәкчелеген Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» МБУ башкара. Ярышларны турыдан-туры уздыру судьялар коллегиясенә йөкләнә:

| Әгерҗе ш. | Бима ав. |
|---|---|
| Баш хөкемдар - Семенов А.Л.<br>Баш сәркәтип - Мөхәммәтҗанова Н.В.<br>Дистанциядә судья - Тукаева Г.Р. | Баш хөкемдар - Яркәев Е.В.<br>Баш сәркәтип - Орехов Г.М.<br>Дистанциядә судья - Михайлов Э.И. |

Чаңгы ярышлары вакытында медицина ярдәме белән тәэмин итү Әгерҗе шәһәрендә «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе»нә, Бима авылында урнашкан Бима авылы ФАПына йөкләнә.

### 4. Ярышларда катнашучылар.

Шәхси ярышлар. Ярышларда чаңгы узышлары буенча спорт әзерлеге булган, медицина тикшерүе узган һәм категорияләр буенча ярышларга табиб кертүче барлык теләүчеләр катнаша ала:

| Әгерҗе ш. | Бима ав. |
|---|---|

| Категория | Дистанция | | Категория | Дистанция | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Егетләр | Кызлар | | Егетләр | Кызлар |
| 09-10 яшь | 1 км | 1 км | 2010 елгы һәм яшьрәкләр | 1 км | 1 км |
| 11-12 яшь | 2 км | 2 км | 2008-2009 елгы | 2 км | 1 км |
| 13-15 яшь | 3 км | 3 км | 2006-2007 елгы | 3 км | 2 км |
| 16-17 яшь | 5 км | 3 км | 2003-2005 елгы | 3 км | 2 км |
| | **Ир-атлар** | **Хатын-кызлар** | | **Ир-атлар** | **Хатын-кызлар** |
| 18-29 яшь | 5 км | 3 км | 18-30 яшь | 3 км | 2 км |
| 30-39 яшь | 5 км | 3 км | 31-50 яшь | 2 км | 1 км |
| 40-49 яшь | 5 км | 2 км | 51 яшь һәм өлкәнрәкләр | 1 км | 1 км |
| 50-59 яшь | 5 км | 2 км | | | |
| 60-69 яшь | 3 км | 2 км | | | |
| 70 яшь һәм өлкәнрәкләр | 3 км | 2 км | | | |

Стиль ирекле, Старт төре - масс – старт.

**5. Җиңүчеләрне билгеләү.**

Шәхси беренчелек үз яшь төркемендә дистанциядә күрсәтелгән ин яхшы вакыт буенча билгеләнә. Үз яшь төркемнәрендә призлы урыннар яулаган катнашучылар грамоталар һәм медальләр белән бүләкләнә.

**6. Финанслау.**

Трасса һәм судьялык әзерләүгә бәйле чыгымнар - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» МБУ исәбеннән. Җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү чыгымнарын кызыксынган оешмалар һәм затлар каплый.

**7. Гаризалар.**

Ярышларда катнашуга гаризалар алдан 2021 елның 12 февраленнән дә соңга калмыйча spshcola@mail.ru электрон адресына жибәрелә. Медицина хезмәткәре тарафыннан расланган катнашуга гаризалар ярышлар уздырылган көнне бирелә. Элемтә телефоннары: 8(85551)2-34-20.

**8. Ярышларда катнашучылар һәм тамашачылар куркынычсызлыгы.**

Барлык катнашучылар, тренерлар, укытучылар, судьялар һәм ярышлар тамашачылары яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралуны булдырмау өчен куркынычсызлык чараларын үтәргә тиеш.

Судьялар, тренерлар, укытучылар һәм катнашучылар чаңгы базасында, ярышларда катнашучыларны теркәгәндә, маскалардан булырга һәм 1,5 м дистанцияне сакларга тиеш.

***Әлеге нигезләмә ярышларга рәсми чакыру булып тора!***

Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы
Башкарма комитетының
04.02.2021 № 17-р
карарына 2 нче кушымта

**ТР Әгерже муниципаль районында «Татарстан чаңгы юлы – 2021» массакүләм чаңгы ярышларын үткәрү өчен Смета, Әгерже шәһәре, Бима авылы, 13.02.20021 ел**

Бүләкләү материаллары:

| | |
|---|---|
| Медальләр | 48 шт. x 100 сум = 4 800 сум |
| Грамоталар | 48 шт. x 15 сум = 720 сум |
| Туклану һәм кайнар чәй | 1000,00 сум |

**БАРЛЫГЫ: 6 520,00 сум**

**ТР Әгерже муниципаль районында «Татарстан чаңгы юлы – 2021» массакүләм чаңгы ярышларын үткәрү өчен Смета, Әгерже шәһәре, Бима авылы, 13.02.20021 ел**

Бүләкләү материаллары:

| | |
|---|---|
| Медальләр | 54 шт. х 100 сум = 5 400 сум |
| Грамоталар | 54 шт. х 15 сум = 810 сум |
| Ягулык Буран (АИ 92) | 75 л. х 42,90 сум = 3 217,50 сум |

**БАРЛЫГЫ: 9 427,50** сум